Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең Чәтбаш авылында 2019 елның 8 ноябрендә кабул ителгән 2/1 нче номерлы "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегенең Чәтбаш авылында 2020 елда үзара салым кертү турында ” халык җыены карары

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Сез

- Чәтбаш авылында су белән цистерна саклау өчен бина төзү;
- Чәтбаш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында гидрантлар һәм башка материаллар, шулай ук эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Чәтбаш авылында калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту һәм рекультивацияләү

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Чәтбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертү белән килешәсезме? «ӘЙЕ» «ЮК» соравы буенча 08.11.2019 үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә

халык җыены карар итте:

1.

- Чәтбаш авылында су белән цистерна саклау өчен бина төзү;
- Чәтбаш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү максатларында гидрантлар һәм башка материаллар, шулай ук эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;
- Чәтбаш авылында калдыкларны вакытлыча җыю урыннарын чистарту һәм рекультивацияләү

эшләрен башкарып җирле мәсьәләләрне чишү максатында тоту өчен шушы җирлектә яшәүче балигъ булган, Чәтбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр кеше исәбеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентларны, бала вакытыннан инвалидларны, коляскалы инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, күп балалы гаиләләрне кертмичә) 2020 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендәге үзара салым кертергә.

2.Халык җыены нәтиҗәләрен информацион стендларда һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә.

Кызылтау авыл җирлеге Башлыгы Ш. Р. Гаффаров